СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

05.03.2018　　　　с. Набережные Моркваши　　　　49-207

«Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 2017 елның 27 декабрендәге 45-193 номерлы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 01.08.2011 № 48-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
Карар итте

1. «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 2017 елның 27 декабрендәге 45-193 номерлы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 2нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган, ә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган җир кишәрлекләре (өлешләре) өчен бары тик бер җир кишәрлеге өчен генә бирелә дип билгеләргә»;

1.2. Әлеге карарның 3нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүче-физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлау буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы»;

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Гаязов